КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 март г.Казань № 162

2021 елга социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының 3 нче кушымтасында китерелгән Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә кушымтаның 15 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучыларның исемлекләрен формалаштыру һәм раслау һәм авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүне башкару турында таныклыклар бирү тәртибенең 19 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен 2021 елга 29,0 мең сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин